СОВЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
18.06. 2026 ел

Карар
№ 1-6

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советының 2024 елның 24 сентябрендәге 1-40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында” 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы “Отарка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советының 2024 елның 24 сентябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 1-40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “2.4 пунктның 2 пунктындагы өченче абзацында “, проектлана торган күрсәткечләре күпфатирлы йорт булган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын төшереп калдырганда” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башлыгы И.И.Фазыловка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге Советы рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы /И.И.Фазылов/